Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы ТатарТау Иле авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге
Княжа торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

23 октябрь, 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы ТатарТау Иле авыл җирлегенең Княжа торак пунктында 2024 елның 23 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 131 (йөз утыз бер).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 67 (алтмыш җиде).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 67 (алтмыш җиде).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2025 елда Княжа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын һәм мәктәп укучыларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- коеларны, аларга якын территорияне төзекләндерү;
- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен җиһазлар тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Татар Тау Иле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Питрәч муниципаль районы
Татар Тау Иле авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Г. Боһараева